**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 нче елның 23 ноябре № 5

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2024 елның 23 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, ветераннардан һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылардан, мобилизацияләнгән гражданнардан, контракт хезмәте хәрбиләреннән тыш, 2025 елда 1000(Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Туктар-Урдаласы торак пунктында Октябрь урамы буенча юлларга вак таш белән җәю; Туктар-Урдаласы торак пунктында Совет, Вахитов, Тукай, Октябрьдә, Куйбышев урамнары буенча юлларны кардан чистарту);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Туктар-Урдаласы торак пунктында Совет урамы буенча карт агачларны кисү)

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 285 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 147 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 147 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, ветераннардан һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылардан, мобилизацияләнгән гражданнардан, контракт хезмәте хәрбиләреннән тыш, 2025 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Туктар-Урдаласы торак пунктында Октябрь урамы буенча юлларга вак таш белән җәю; Туктар-Урдаласы торак пунктында Совет, Вахитов, Тукай, Октябрьдә, Куйбышев урамнары буенча юлларны кардан чистарту);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Туктар-Урдаласы торак пунктында Совет урамы буенча карт агачларны кисү)

соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар-Урдаласы авылы, административ бинада Совет ур., 98 йорт, мәдәният йорты бинасында Совет ур., 103 йорт, Карагай авылы КФҮ бинасында Тельман ур., 31 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Туктар-Урдаласы авыл җирлеге башлыгы Г.Ә.Әхмәтова